СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.08.2025 № 61/4

На №________ от__________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 29 мартындагы 31/12 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Тукай муниципаль районында яшәүчеләрнең җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын тәэмин итү, Тукай муниципаль районында территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру өчен хокукый һәм оештыру нигезен булдыру максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 29 мартындагы 31/12 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктчаны өстәргә:

«7) инициатив проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров